| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.11.2017 Казан ш. № 10-30/кс

2018-2020 елларга «Татэнерго» акционерлык җәмгыятенең Чаллы ТЭЦ филиалы өчен салкын суны транспортлауга һәм агынты суларны транспортлауга тарифлар билгеләү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне гамәлгә ашыручы «Татэнерго» акционерлык җәмгыятенең Чаллы ТЭЦ филиалы өчен салкын суны транспортлауга һәм агынты суларны транспортлауга шушы карарның 1 нче кушымтасы нигезендә, календарь буенча бүлеп, тарифлар билгеләргә.

2. Шушы карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2018 елның 1 гыйнварыннан башлап 2020 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне гамәлгә ашыручы «Татэнерго» акционерлык җәмгыятенең Чаллы ТЭЦ филиалы өчен 2018-2020 елларга салкын суны транспортлауга һәм су бүлүгә тарифларны җайга салуның, шушы карарның 2 нче кушымтасына туры китереп, дәвамлы параметрларын билгеләргә.

3. Салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне гамәлгә ашыручы, шушы карар кушымтасында күрсәтелгән «Татэнерго» акционерлык җәмгыятенең Чаллы ТЭЦ филиалына Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә

мәгълүмат ачу стандартларына туры китереп, ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турындагы карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитетының 10.11.2017 № 10-30/кс
карарына 1 нче кушымта

# Салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне гамәлгә ашыручы «Татэнерго» акционерлык җәмгыятенең Чаллы ТЭЦ филиалы өчен салкын суны транспортлауга һәм агынты суларны транспортлауга 2018-2020 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Салкын суны транспортлауга тариф (бер ставкалы), сум/куб м. | | | | | | Агынты суларны транспортлаган өчен тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2018 ел | | 2019 ел | | 2020 ел | | 2018 ел | | 2019 ел | | 2020 ел | |
| | | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 |
| | «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге | | | | | | | | | | | | |
| 1 | «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте | | | | | | | | | | | | |
| 1.1 | «Татэнерго» акционерлык җәмгыятенең Чаллы ТЭЦ филиалы (тарифлар НДС исәпкә алмыйча күрсәтелде) | 0,61 | 0,62 | 0,60 | 0,60 | 0,59 | 0,59 | | | | | | |
| 1.1.1 | Технологик яктан үзара бәйләнмәгән берничә үзәкләштерелгән система булуга карап, тарифларны дифференциацияләштерү: | | | | | | | | | | | | |

| № п/п | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Салкын суны транспортлауга тариф (бер ставкалы), сум/куб м. | | | | | | Агынты суларны транспортлаган өчен тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2018 ел | | 2019 ел | | 2020 ел | | 2018 ел | | 2019 ел | | 2020 ел | |
| | | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 |
| 1.1.1.1 | Сәнәгатьтәге җыентык суларны су бүлү | | | | | | | 1,05 | 1,05 | 1,05 | 1,06 | 1,06 | 1,06 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт
комитетының 10.11.2017 № 10-30/кс
карарына 2 нче кушымта

## Салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне гамәлгә ашыручы «Татэнерго» акционерлык җәмгыятенең Чаллы ТЭЦ филиалы өчен 2018-2020 елларга салкын суны транспортлауга һәм су бүлүгә тарифларны җайга салуның дәвамлы параметрлары

| № п/п | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су бүлүне гамәлгә ашыручы оешманың аталышы, Тариф төре | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Суны югалту дәрәҗәсе | электр энергиясенең чагыштырма сарыфы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·с/куб.м |
| 1 | «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте | | | | | | |
| 1.1 | «Татэнерго» акционерлык җәмгыятенең Чаллы ТЭЦ филиалы | | | | | | |
| 1.1.1 | Салкын суны транспортлау | 2018 | 5,18 | 1 | - | - | - |
| | | 2019 | 5,39 | 1 | - | - | - |
| | | 2020 | 5,60 | 1 | - | - | - |
| 1.1.2 | Агынты суларны транспортлау | 2018 | 336,93 | 1 | - | - | - |
| | | 2019 | 350,41 | 1 | - | - | - |

| № п/п | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су бүлүне гамәлгә ашыручы оешманың аталышы, Тариф төре | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Суны югалту дәрәҗәсе | электр энергиясенең чагыштырма сарыфы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·с/куб.м |
| | | 2020 | 364,43 | 1 | - | - | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге